**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

31.08.2018 г. № 340

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының
Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтү шартларының
сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүче Иҗтимагый советы оешмасы
Нигезләмәсен раслау турында.

2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы "Россия Федерациясенең мәдәният өлкәсендә, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә һәм Федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан сыйфатлы хезмәт күрсәтүне камилләштерү мәсьәләләре буенча аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында Нигезләмә расларга.
2. 2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы В. С. Гайнетдиновка йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.

Кушымта

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында кушымта.

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1 Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет (алга таба - сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы киңәшмә органы булып тора (алга таба-ТР ӘМР Башкарма Комитеты) - Ул Татарстан Республикасында гражданнарның мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфаты, аларның эшчәнлеген камилләштерү турындагы мәгълүматтан файдалану хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

1.2 Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм Күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, муниципаль хокукый актларга,шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3 Мәдәният, мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен үз эченә алган Иҗтимагый совет карары тарафыннан мәдәният, мәгариф һәм аларның җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча чаралар эшләп чыгарганда һәм аларның эшчәнлеген яхшырту буенча тәкъдимнәр кергән көннән алып бер ай эчендә ТР ӘМР башкарма комитеты тарафыннан каралырга тиеш.

1.4 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

1.5 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет граждан җәмгыяте институтлары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең үзара хезмәттәшлеге нигезендә үз эшен башкара.

1.6 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат ТР ӘМР башкарма комитеты тарафыннан "Интернет"

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - "Интернет" челтәре) ТР Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

1.7 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмә ТР ӘМР башкарма комитеты тарафыннан раслана.

## 2 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре.

2.4 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып тора:

муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан һәм мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче башка оешмалар тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетларының бюджет ассигнованиеләре хисабына хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына иҗтимагый контрольне көчәйтү;

тиешле өлкәдә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.5 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның бурычлары булып тора:

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя бирү;

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Т.Р. ӘМР башкарма комитеты карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүнең сыйфаты турында җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын арттыру.

2.6 сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советка йөкләнгән бурычлар:

сыйфатны бәйсез бәяләү үткәрелә торган оешмалар исемлеген билгели;

Т.Р. ӘМР башкарма комитеты тарафыннан эш, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турындагы документлар проектларын, шулай ук мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары турында мәгълүмат җыю һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешма белән төзелә торган дәүләт контракты проектын (алга таба - оператор) карауда катнаша;

оператор биргән мәгълүматны исәпкә алып, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя бирәләр;

ТР ӘМР башкарма комитетына мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук аларның эшчәнлеге сыйфатын яхшырту турындагы тәкъдимнәрне тәкъдим итә.

3 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составы.

3.4 Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Башкарма Комитеты мөрәҗәгате буенча Иҗтимагый советы әлеге мөрәҗәгать алынган көннән бер айдан да соңга калмыйча сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет формалаштыра һәм аның составын раслый.

3.5 Бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет гражданнарның, инвалидларның, иҗтимагый берләшмәләренең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында булдырылган иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән төзелә.

3.6 Иҗтимагый совет тарафыннан муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан мәдәният һәм мәгариф оешмалары һәм мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче башка оешмалар тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетының бюджет ассигнованиеләре хисабына хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатына бәйсез бәя бирелә.

3.7 Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының иҗтимагый советы ӘМР башкарма комитетына әлеге органнар каршында оештырылган сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның составы турында хәбәр итә.

3.8 Әлки муниципаль районы башкарма комитеты сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составы раслангannнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый советның сыйфатны бәйсез бәяләү буенча беренче утырышын үткәрүне оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе һәм рәиснең урынбасары сайлана. Карар ачык тавыш бирү юлы белән сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.9 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисен яисә рәис урынбасарын вазыйфадан азат итү мәсьәләсе Иҗтимагый совет тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисенә, ТР ӘМР башкарма комитеты җитәкчесе мөрәҗәгате буенча, шулай ук сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасарының шәхси гаризасы буенча яисә сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил итүче төркем тәкъдиме буенча карала. Карар сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.10 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый Советның җаваплы секретарен сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан билгели.

3.11 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составы өч елга раслана.

Иҗтимагый советны яңа срокка формалаштырганда составының өчтән береннән ким булмаган өлеше үзгәртелә.

3.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составына вәкилләр керә алмый:

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары;

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләр;

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмалар җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре.

3.12 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет үз эшенә мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасы вәкилләрен фикер алышу һәм нәтиҗәләрне формалаштыру өчен җәлеп итә.

3.13 Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

3.14 Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Татарстан Республикасы Әлки муниципаль берәмлеге Иҗтимагый советы рәисе карары белән Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча түбәндәге очракларда туктатыла:

аңа Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләү белдерү;

административ арест рәвешендә аңа административ җәза билгеләү;

дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатына кандидат, җирле үзидарә органына сайлау вазыйфасына кандидат, ышанычлы зат яисә сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле сыйфатында, шулай ук аны Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта теркәү.

3.13. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләре срогы чыккач;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза бирү;

сәламәтлеге буенча сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшендә катнашуга яраксыз булу;

аңа карата чыгарылган суд карары үз көченә керү;

закон көченә кергән суд карары нигезендә аны эшкә яраксыз яисә кайдалыгы билгесез дип тану;

этик нормаларын тупас бозган өчен Ижтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән карары буенча;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет утырышларының эшендә системалы (өч тапкырдан артык) җитди сәбәпсез катнашмау-сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавыш белән кабул ителгән карары буенча;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары күрсәтмәләрен нигезле сәбәпләрдән башка үтәмәгән очракта бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавыш белән кабул ителгән карары нигезендә;

Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта;

ике гражданлык алган очракта;

Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу.

3.14. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Татарстан Республикасы Ижтимагый палатасы рәисе карары нигезендә, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасарының язма гаризасы нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13 пунктында каралган хәлләр ачыкланган очракларда гамәлгә ашырыла.

## 4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары.

4.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Ижтимагый совет әгъзасы хокуклы:

мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның эшчәнлеген бәяләүгә,Т.Р. ӘМР башкарма комитеты инициативасы буенча үткәрелә торган хезмәт күрсәтү шартларына кагылышлы барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, "түгәрәк өстәл "ләрдә һ. б.) катнашырга, моңа дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалану белән бәйле рәвештәге, шәхси мәгълүматлар һәм федераль законнар нигезендә рөхсәт ителми торган чикләнгән мәгълүматлардан торган чаралар керми;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советка аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү һәм инициатив тәртиптә җибәрү;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның сыйфатны бәйсез бәяләү буенча эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертү;

көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне карауда катнашу өчен сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышына чакырылган затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары составыннан чыгу.

4.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан кушылган йөкләмәләрне үтәргә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның Нигезләмәсендә күрсәтелгән эшләү тәртибен белү һәм үтәү;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет тарафыннан төзелә торган эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, башка эш органнары эшендә катнашырга.

5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның эш тәртибе.

5.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет утырышында расланган планнар һәм программалар нигезендә үз эшен оештыра.

5.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе һәм ТР ӘМР башкарма комитеты тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.4. Әгәр дә утырышта сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый Совет Әгъзаларының өчтән икесеннән дә ким булмаган өлеше катнашса, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышлары дөрес дип санала. Утырышта шәхси катнашу мөмкинлеге булмаган очракта Иҗтимагый

совет әгъзасы, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның башка әгъзасына язмача, факсимиль яки электрон почта аша көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз фикерен һәм тавышын, алдан ук бу хакта сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәис урынбасарына хәбәр итеп, тапшырырга хокуклы. Алар утырышта катнашучылар арасында дип санала һәм тавышлары исәпләнелә.

Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет карарлары күпчелек тавышы белән кабул ителә.

5.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышын сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаганда - сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе:

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының сыйфатны бәйсез бәяләү буенча тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эшенең сыйфатын бәйсез бәяләү буенча планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет раславына тәкъдим итә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышын оештыра;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет тәкъдимнәрен, Иҗтимагый советның сыйфатны бәйсез бәяләү буенча беркетмәләрен һәм башка документларын имзалый;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге кысаларында, аңа йөкләнгән максат һәм бурычларны истә тотып, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет исеменнән сораулар, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләр яза;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмаган очракта аның функцияләрен башкара;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның көн тәртибен төзи һәм сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисенә раслау өчен тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле булган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый Советның җаваплы сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм проект карарларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибе, үткәрү урыны һәм вакыты турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллары белән тәэмин итә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый советның һәм ТР ӘМР башкарма комитетының хезмәттәшлеген тәэмин итә;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген документлар һәм техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен төзи һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;

сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышында тыңлауга һәм фикер алышуга мәсьәләләр әзерләү өчен Иҗтимагый совет әгъзалары эшче, эксперт төркемнәренә һәм башка эшче органнарга берләшергә, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештереп, материаллар әзерләүгә җәлеп итәргә мөмкин.

5.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет карары нигезендә, сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышына башкарма органнар, ТР җирле үзидарә органнары, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет әгъзалары булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнаша алалар.

5.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет утырышы билгеләнгән көнгә кадәр ун календарь көннән дә соңга калмыйча

тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак тапшырган очракта сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет рәисе яисә Рәисе урынбасары белән килештерелә.

5.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыруны һәм техник яктан тәэмин итүне ТР ӘМР башкарма комитеты гамәлгә ашыра.